УДК 728.03

***И.И. Халикова***

# Ф. ХАЛИКОВ ӘСӘРЛӘРЕНДӘ БОРЫНГЫ КАЗАННЫ СУРӘТЛӘҮ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

Статья посвящена анализу произведений известного художника Республики Татарстан, академика Российской Академии художеств Фирината Халикова. По архивным документам, зарисовкам и устным преданиям он выстроил исторический облик древнего города в жанре реконструкций. В его картинах раскрывается величие и исторический масштаб ханской Казани.
**Ключевые слова:** творческая мастерская Российской Академии художеств в Казани, история, ханская Казань, интерпретация, реконструкция.

The article is devoted to the analysis of the works of the famous artist of the Republic of Tatarstan, academician of the Russian Academy of Arts Firint Khalikov. On the basis of archival documents, sketches and oral legends, he built the historical appearance of the ancient city in the genre of reconstructions. The greatness and historical scale of Khan's Kazan is revealed through works of art.
**Keywords:** creative workshop of the Russian Academy of Arts in Kazan, history, Khan Kazan, monumental architecture, art, artist, exhibition, exposition.

Казан – Идел елгасының сул ярында урнашкан шәһәр, Татарстан Республикасы башкаласы, Россиянең мөһим икътисади һәм мәдәни үзәге. Ул – күп гасырлык тарихы булган борынгы шәһәр генә түгел, ә Европа белән Азия, православие белән ислам мәдәниятләре кисешкән урын да. Моннан 1000 еллар элек Идел Болгарының төньяк өлешендә Киев Русеннан, Византия империясеннән һәм Якын Көнчыгыштан агылган сәүдә кәрваннарының очрашу урыны буларак ныгытма төзелә. Шәһәрнең яшен Казан Кремле территориясендә археологик казу эшләре вакытында табылган таш корылмалар, агачтан эшләнгән койма калдыклары, көнкүреш әйберләре, шулай ук 929–930 еллар белән даталанган чех тәңкәсе буенча билгеләделәр [Садриев, 2016, с. 161–172].

1438 елда болгарлар тарафыннан төзелгән ныгытылган корылма Алтын Урда ханы Олуг Мөхәммәд гаскәрләренең каты һөҗүменнән соң Казан ханлыгының башкаласына әйләнә [Золотоордынское обозрение, 2014, с. 15]. Рус елъязмаларында Казан XIV–XV гасырлардан искә алына башлый. Алтын Урда дәүләте составында мөһим сәяси һәм сәүдә үзәгенә әверелеп, Казан каласы актив үсеш кичерә. Казанның үсүе һәм ныгуы хәрби низагларсыз гына да бармый. Мәскәү кенәзлеге белән ике арадагы ызгыш-талашлардан соң, 1552 елда Явыз Иван гаскәрләре Казанны яулап ала, шәһәрнең зур өлеше җимерелә, ә татарларны Кабан күленең сазлыклы яр буйларына күчерәләр,

анда соңрак Иске Татар бистәсе барлыкка килә. Казан краенда баш күтәрүләр бастырылганнан соң, шәһәр Россия дәүләте белән бәйле яңа чорга аяк баса.

Урта гасырлар Казанының тарихын өйрәнү һәрвакыт актуаль булды һәм бу өлкәдә яңадан-яңа ачышлар ясала тора. XIX–XX гасыр башында татар тарихы фәне барлыкка килгәннән соң, тикшеренүчеләр татар тарихын, нигездә, төрки-татар фольклорына, төрки этнографик елъязмаларга һәм лингвистик материалларга, шулай ук гарәп, фарсы тарихи документларына, Россия һәм Төркия тарихчыларының хезмәтләренә таянып өйрәнәләр. Хөсәен Әмирхан, Шиһабетдин Мәрҗани, Каюм Насыйри, Һади Атласи һ.б. кебек мәшһүр затларыбызның хезмәтләре нигезендә татар халкы тарихы формалаша башлый.

Тарихи нәкыш – тематик картинаның иң катлаулы жанрларыннан берсе. Моңарчы да татар сәнгатендә популяр булган милли тарих һәм тарихи нәкыш темасы 1920–1930 кабаткүтәрелеш кичрә. XX гасыр бүтәнчәрәк кыйммәтләргә өстенлек бирә: 1960 еллар ахырына кадәр Татарстан рәссамнары әсәрләрендә милли тема һәм тарих этнографизм һәм типаж дәрәҗәсендә генә ачыла. Казанның архитектура символы булган Сөембикә манарасы сурәтләре, Касыйм шәһәре (бәреп төшерелгән ханбикәнең соңгы сыену урыны) пейзажлары А.И. Трапицын, С.О. Лывин, В.В. Анютин, Р.А. Гыйләҗев, Г.Л. Эйдинов картиналарында урын ала.

1970–1980 елларда Татарстан тарихи нәкыше панорамасында Ч.Г. Әхмәров, Б.И. Урманче, И.К. Зарипов, Ә.И. Тумашев, К.А. Нәфыйков, Р.М. Вахитов тарафыннан үз чоры өчен яңа әсәрләр языла. Тарихка тирән хөрмәт атмосферасында иҗат итү бу осталарның сәнгатьтә үз юлларын табуында хәлиткеч роль уйный. Бакый Урманче ханнар чоры Казанын Сөембикә образы аша ача (ханбикәнең скульптур портреты яки аксакал сәнгатькярнең график әсәре) [Татарский мир, 2019, с. 372–385]. Шәркый Урта Азия Р.М. Вахитов иҗатына да үз эзен салган. Борынгы Көнчыгыш миниатюрасына охшатып сәнгатьчә стильләштерү алымнары яссы композицияләрдә, төрле төстәге тапларының локаль һәм ачык булуында, офыклар юклыкта чагыла.

Бу осталарның эшләрендә иҗади хыялның бик көчле булуы сизелә. Темаларның һәм сәнгати алымнарның гаҗәеп төрлелегендә төптән уйланылган стиль һәм сәнгати-образлы система тоемлана. Нәтиҗәдә алар иҗатында татар халкының мәдәни истәлекләре, гореф-гадәт һәм йолалары яңа сулыш ала. Нәкыш осталары, архитектураның бөеклеген һәм тантаналылыгын данлап, үз картиналарында мигъмарият пейзажын сурәтлиләр, ерак тарихта калган мәдәниятләрне чагылдыралар.

1980–1990 еллар чигендә милли теманы аңлауда яңа этап башлана. Ф.Г. Халиков иҗатының башлангыч чорында борынгылыкны һәм татар тарихын өйрәнү өстенлек итә. Рәссамның әсәрләренә теманы ышанычлы итеп, җентекләп эшләү хас, ә стилистикада ул рус тарихи

нәкыше (И. Репин, В. Суриков) традицияләренә якын тора [Программа подготовки к празднованию...].

Тарихи темаларга язылган масштаблы полотнолары белән популярлык казанган зур рәссам Ф. Халиков үзенең әсәрләрендә татар тарихының драматик сәхифәләрен гәүдәләндерә. Һәм моны ул, рәссам һәм гражданин буларак, үзенең миссиясе дип саный [Фиринат Халиков, 2012, с. 23]. Аның туган халкының үткәне белән кызыксынуына хәзерге заманда күтәрелгән мәсьәләләр сәбәп була [Современное искусство художников Татарстана, 2005, с. 134].

Сәнгать өлкәсендә башлангыч белемне Ф. Халиков Киров сәнгать училищесында ала (1979–1983). Профессиональ сәнгати белемгә ия булганнан соң, реалистик нәкышнең пленэр пейзаж жанрында эшли.

Казанда Россия Рәссамнар академиясенең иҗат остаханәләренә кергәч (1993), Болгар шәһәренә багышланган әсәрләр циклына тотына. Татарларның килеп чыгышы белән кызыксынуы нәтиҗәсендә 1994 елда ул тарихчы һәм археолог, татар халкы тарихы буенча күпсанлы хезмәтләр авторы Альфред Халиков белән таныша. Фәнни-популяр әдәбият нәшер итү аларның уртак эшенә әйләнеп, басмаларда тарихи реконструкция Ф. Халиковның иллюстрацияләре рәвешендә урын алырга тиеш була. Рәссам, татар халкының тарихын өйрәнү максаты белән, ирекле тыңлаучы сыйфатында Казан университетында укый башлый.

Ф. Халиков тарихи пейзаж жанрында (1995) үз иҗатының төп темасы итеп Казан ханлыгы чәчәк аткан чорны сайлый һәм «Мәңгелек Казан» циклын башлап җибәрә. Аның иҗатында бу тема күбесенчә әлеге шәһәр тарихына карата гомуми кызыксыну уяну белән бәйле була [Фиринат Халиков, 2005, с. 27].

Казан шәһәренең 1000 еллыгын бәйрәм итүгә әзерлек барганда Ф. Халиковның беренче шәхси күргәзмәсе оештырыла. Ул 1996 елның җәендә «Казан» милли мәдәният үзәгендә уза. Күргәзмәдә рәссамның түбәндәге төп эшләре тәкъдим ителә: «Казан өчен сугыш» (1996), «XVI гасырда Казанда кышкы кояшлы көндә» (1996), «Болак ягыннан кышкы Казан» (1996) һ.б.

Шәһәр тарихын өйрәнү белән тарихчылар да, төбәкне өйрәнүчеләр дә, шул исәптән чит ил кешеләре дә җитди шөгыльләнә башлый. Казан шәһәре хакимияте шәһәрнең меңьеллыгы концепциясен әзерләү буенча фәнни-теоретик эш алып бара [Программа подготовки к празднованию...]. Республикада һәм аннан читтә Казанга нигез салыну датасын билгеләү буенча киң күләмле эш җәелдерелә, Казан Кремлендә археологик эзләнүләр башлана, нәтиҗәдә Казанның яулап алынуын яктырткан моңарчы билгеле булмаган чыганаклар билгеле була [Фиринат Халиков, 2012, с. 32]. Ф. Халиков фәнни материалны җентекләп өйрәнә, архив документлары белән эшли, тарихи, археологик, әдәби һәм этнографик мәгълүматларны анализлый. Әзерлек эшләренең башлангыч стадиясендә аның тарафыннан эскизлар һәм караламалар эшләнә.

Ф. Халиков, шулай итеп, беренчеләрдән булып Урта гасырлар Казанының иконографиясен фәнни нигезгә куя. Архив документлары, рәсемнәр һәм телдән сөйләнгән риваятьләр буенча ул реконструкция жанрында борынгы шәһәрнең архитектурасын торгыза («Казан Кремленең барлыкка килү этаплары») [Фиринат Халиков, 2017, с. 7]. Архитектура пейзажында аның барлык элементларының пространствода урнашуын сурәтләү аеруча мөһим. Моның өчен перспективаны да, буяулар нисбәтен дә дөрес күрә белергә кирәк. Барыннан да элек, җирнең яссылыгын һәм күкнең киңлеген дөрес сурәтли белү зарур.

Рәссам үз картиналарында шәһәрнең гүзәл панорамасын тәфсилләп сурәтли. Ерак ата-бабаларыбыз белән багланышны яңадан торгызуга, үткәндәге архитектураны, шәһәрне реконструкцияләүгә омтылыш ачык чагыла. Ф. Халиков һәрвакыт яңа ракурс, «кош очышы» биеклегеннән яңа ноктаны, ел фасылын, шәһәр тормышындагы вакыйгаларны, киң антураж һәм стаффаж сайлый, шәһәрнең чуарлыгын ватандашларының йөрәгендә сакларга тырыша [Фиринат Халиков, 2012, с. 34]. Рәссам картинада Казан ханлыгының тарихи образын гына түгел, ә һәр чорда барган вакыйгаларны да гәүдәләндерү бурычын куя. Шулай итеп, ул татар риваятьләрендә һәм рус елъязмаларында тасвирланган затларны, күренекле шәхесләрне сурәтли.

Полотноларда чагылдырылган сюжетлар күп фигуралы, жанрлы. Бигрәк тә Сөембикә, Олуг Мөхәммәд, Шаһгали, Иван Грозный кебек тарихи шәхесләргә багышланган сюжет линияләрен аерып күрсәтергә мөмкин. Дөнья һәм рус тарихи нәкышендә танылган рәссамнар полотнода сюжетларны халык төркеме фонында чагылдыралар. Ф. Халиков та татар халкын беренче планга чыгарып, шул үрнәккә иярә. Ул халык төркемен картина пространствосын тутыру өчен түгел, ә татар халкының бөеклеген чагылдыру өчен бирә. Ф. Халиков картиналарында халык – вакыйгада катнашучы гына түгел, аеруча мөһим миссия үтәүче [Фиринат Халиков, 2012, с. 37].

Рәссамның «Мәңгелек Казан» сериясенә караган эшләре арасында «Нурлы Казан» (1997) – күп фигуралы һәм масштаблы картиналарның берсе. Картина Бөтендөнья татар конгрессының II корылтае уңаеннан языла. Полотно өстендә эшләү барышында Ф. Халиков Казанның тарихи архитектурасын һәм ландшафтын гына түгел, ә мәдәни образын да тудыру өчен, көнчыгыш костюмы һәм коралы буенча китапларны тирәнтен өйрәнә. Төп идеяне булдыруда Н. Халитовның Кремль архитектурасы буенча фәнни хезмәте зур роль уйный. Аның фикеренчә, Казандагы хан сарае цитадельдән һәм административ үзәктән тора, соңгысында сарай, диванханә, төрбәләр, сарай мәчете, гвардия һәм хәрәмле хан резиденциясе, казна, хезмәтчеләр өчен биналар урнашкан һәм ул ныгытма дивары белән әйләндереп алынган [Халитов]. Әмма төрле сәбәпләр аркасында аларның уртак эше барып чыкмый, бу рәссам һәм галимнең ханнар чоры Казаны панорамасының форма һәм масштабларына карашлары төрле булу белән бәйле.

Безнең көннәргә Казанның 1701 елга кадәрге шул дәвердә яшәгән рәссамнар тарафыннан ясалган ике гравюрасы гына килеп җиткән. Аларның берсе – Казан Кремленең панорамалы күренеше [Валеев, Валеева-Сулейманова, 2002, с. 82]. Ул Адам Олеарий тарафыннан башкарылган һәм аның Голштин илчелегенең Фарсы иленә сәяхәтен тасвирлаган китабының икенче басмасына (1656) кертелгән. Әлеге гравюра, Адам Олеарий сурәтенең ышанычлы булу-булмавы галимнәр тарафыннан берничә тапкыр шик астына куелуга карамастан, рәссамны иҗатка рухландыручы төп чыганак булып тора [Хузин, Ситдиков, 2005, с. 16].

Архитектура һәм сәнгати стиль формаларын интерпретацияләгәндә, Ф. Халиковка татар шәһәр мәдәниятенең күп кенә югалган таныклама-дәлилләрен, иҗади якын килеп, яңадан тудырырга туры килә. Рәссам тарафыннан алдан ясалган биш реконструкция «Нурлы Казан»ны иҗат иткәндә аеруча әһәмиятле роль уйный. Алар «Казан шәһәренең барлыкка килү этаплары» дип атала, һәм аның туу, гөрләп чәчәк ату чорларын, тарихның борылыш мизгелләрен һәм халык фаҗигаларын чагылдыра. Һәр картина шул үзенчәлеге белән әсир итә: ракурс биеклектән алынган, бу исә шәһәрнең үсеш һәм формалашу этапларын күзәтеп барырга мөмкинлек бирә, борынгы фоторәсем яки киноленталарны карау тәэсире тудыра.

Югарыгы үрдән – дозор манарасы башыннан, күләмнәрне чамалап, күз карашы аска тәгәри һәм сюжетның кульминацион ноктасы – халыкның һәм җиңү яулаган гаскәрләрнең матур чатырда урнашкан патшабикә җитәкчелегендәге хан яраннары белән очрашуы күренешенә барып тоташа. Казан халкы регентша белән очрашуга килгән – баш иеп сәламләргә һәм хәер-фатиха алырга. Гаскәр исә – тугрылыкка ант бирергә. Атлылар төркеме башындагы хәрби җайдак – Казан гвардиясе башлыгы. Мәйданда – сәүдә кибетләре, Көнчыгыш товарлары белән сату-алу бара, ә уңда – чәйханә, аның чуар киемле музыкантлары балконда урнашкан [Фиринат Халиков, 2017, с. 63].

Зур күләмле полотноның максаты – Казанны Казан ханлыгының башкаласы буларак гәүдәләндерү, халыкның «нурлылыгын», шәһәр архитектурасын, татар милли киемен күрсәтү. Бу – үткәнне бүгенге белән бәйли алган, Татарстан Республикасында Казан тарихы турында сөйләүче бердәнбер күп фигуралы, жанрлы һәм тарихи картина.

Яңадан торгызылган Казан образлары рәссам алдына яңа бурычлар куя: шәһәрнең тарихи образын гына түгел, ә анда барган вакыйгаларны да аңларга кирәк.

Урта гасырлар Казанына эчке яктан күз салыйк. Сөембикә ханбикәгә багышланган картиналар сериясе – рәссам шәһәр пространствосын һәм кешеләрне җентекләп сурәтләгән полотноларның берсе. Ханбикә турындагы өч картина (аларны триптих итеп тә карарга була) аның тормышының төрле чорлары турында сөйли. Иң масштаблы һәм эчтәлеге буенча шактый зур эшләрнең берсе – «Сөембикә

белән хушлашу» (2001). Рәссам Казан корылмаларының зур булмаган бер өлешен, ханбикәсен озатучы халыкны күрсәтә.

Полотнода сурәтләнгән күңелсез табигать тә – болытлар белән капланган күзгә соры күк йөзе, елга өстеннән килгән салкынлык һәм томан эченә кереп югалган офыклар – ханбикәсен озата бара кебек. Казан әле матурлыгы белән таң калдыра, аның җимерелер көннәре әле алда [Фиринат Халиков, 2012, с. 58].

Алтын киемнәр кигән ханбикә кояш кебек якты, ул улы Үтәмешне үзенә сыендырган һәм озатырга килгән халыкка моңлы-сагышлы карашын ташлый. Кешеләрнең күзләрендә дә шушы ук моң-зар, коточкыч зур югалту ачысы. Архитектурада таш корылмалар, мәчетләр, хан төрбәләре өстенлек итә, әмма агач корылмалар да, шәһәрнең дошманнан саклану диварлары да бар. Таш биналарның алгы якларында милли орнамент һәм гарәп язуы төшерелгән.

Ф. Халиков – Н. Фешин һәм П. Беньков чорларыннан югала башлаган классик реалистик сәнгать кануннары системасын тулаем үзләштергән тәүге рәссамнарның берсе. Аның ата-бабаларыбызның бөеклеген һәм иң яхшы сыйфатларын колачлаган картиналары гаять зур әхлакый-тәрбияви әһәмияткә ия.

Рәссам бүген дә тарихи жанр өстендә эшләүдән туктамый. Сәнгать әсәрләрендә тарихның яңадан-яңа сәхифәләрен ача. Тамашачыны яңа белемнәр белән баета, Урта гасырлар Казан ханлыгы тарихының матурлыгына карап сокланырга өйрәтә.

Рәссам Ф. Халиковның иҗаты Казанның борынгы тарихы, аның барлыкка килү вакыты белән кызыксынуны арттырды, шулай ук Казан Кремле ансамбленең ЮНЕСКО Бөтендөнья мәдәни һәм табигый мирасы «Исемлеге»нә кертелүенә булышлык итте. Рәссам Ф. Халиков иҗат иткән полотналарны киң җәмәгатьчелек Татарстан һәм Россия сынлы сәнгатендәге әһәмиятле күренеш дип таныды. Рәссамның картиналары илебезнең 15 музее фондларында, шул исәптән Казан һәм Мәскәү музейларында, шулай ук АКШ һәм Финляндиядәге шәхси коллекцияләрдә саклана.

**Әдәбият**

*Валеев Ф.Х., Валеева-Сулейманова Г.Ф.* Древнее искусство Татарии. Казань: Татар. кн. изд-во, 1987. 166 с.

*Валеев Ф.Х., Валеева-Сулейманова Г.Ф.* Древнее искусство Татарстана. Казань: Татар. кн. изд-во, 2002. 104с.

Золотоордынское обозрение: Сборник статей. 2014. № 2 (4).

Программа подготовки к празднованию 1000-летия основания г. Казани от 3 марта 2001 года. № 295-р. // https://izo-museum.ru/hazine/vyistavki-i-sobyitiya/hudojniki-tatarstana-obraz-syuyumbike--posledney-tsaritsyi-kazanskogo-hanstva-v-kanun-500-letiya-so-dnya-rojdeniya. Дата обращения: 05.09.2021.

*Садриев Н.Р.* История изучения городской застройки ханской Казани // Поволжская археология. 2016. № 4 (18). С. 161–172.

Современное искусство художников Татарстана / [текст Дина Валеева, Розалина Шагеева]; [фот. Газинур Хафизов, Марат Гарифзянов, Гульнара Сагиева]. Казань: Татар. кн. изд-во, 2005. 384 с.: ил.

Татарский мир / авторы-сост.: Г.Ф. Габдрахманова, Э.М. Галимова, Д.Ф. Загидуллина, И.Л. Измайлов, А.Р. Салихова, А.Г. Ситдиков, Л.М. Шкляева. Казань: Заман, 2019. 392 с.: ил.

Творческая мастерская живописи в Казани. – Казань: Заман, 2015. – 112 с.: ил.

Фиринат Халиков. Вечная Казань / Текст: *Р.Г. Шагеева*. Казань: Заман. 2005. 192 с.: ил. (Мастера живописи)

Фиринат Халиков. Графика. Скульптура. Дизайн. Казань: Заман, 2012. 208 с.: ил.

Фиринат Халиков: [альбом] / [авторы текста: Р.Г. Шагеева, Р.Р. Магдеев]. Москва: Белый город: Воскресный день, 2017. 63, [1] с.: цв. ил., цв. портр.; 32 см. (Мастера живописи).

*Халитов Н.Х.* Исчезнувшие архитектурные комплексы и памятники Кремля. Источник http://www.rusarch.ru/halitov2.htm

*Хузин Ф.Ш., Ситдиков А.Г.* О локализации в Казанской крепости исторической мечети Кул Шарифа // Гасырлар авазы = Эхо веков. 2005. Вып. 2.

***Халикова Ирина Илдар кызы,***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институты аспиранты;*
*Азнакай төбәкне өйрәнү музее директоры*